ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

02.11.2020 — № 887

2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы җирле үзидарә органнарын мәгълүматлаштыру буенча максатчан программаны кабул итү турында

«Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм мәгълүматлаштыру турында» 2007 елның 13 ноябрендәге 58-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, «Татарстан Республикасында мәгълүмати һәм коммуникацион технологияләрне үстерү һәм куллану» республика максатчан программасын, «Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, башкарма хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлек мәсьәләләре буенча гражданнарга һәм оешмаларга мәгълүмати-белешмә ярдәменең бердәм системасы турында» 2009 елның 15 июнендәге 478 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарын гамәлгә ашыру максатларында,

КАРАР БИРӘ:

1. «2021 - 2023 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының җирле үзидарә органнарын мәгълүматлаштыру программасын (алга таба - Программа) расларга.

2. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУнә, Программаны гамәлгә ашыру срокларын исәпкә алып, Программа нигезендә чараларны финанслауны тәкъдим итәргә.

Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче — Р.Р. Хәмзин

2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының җирле үзидарәсен мәгълүматлаштыру программасы

Программаның Паспорты

| | |
|---|---|
| Программа атамасы | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының 2021 - 2023 елларга җирле үзидарәсен мәгълүматлаштыру программасы (алга таба - Программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез | - «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында».2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы Федераль закон.<br>- «Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм мәгълүматлаштыру турында» 2007 елның 13 ноябрендәге 58-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы.<br>- 2008елның 7 февралендә Россия Федерациясе Президенты тарафыннан расланган Пр-212 номерлы Россия Федерациясендә мәгълүмати җәмгыятне үстерү стратегиясе;<br><br>- «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон<br><br>«Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы Федераль закон;<br><br>- «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль закон;<br><br>- «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон;<br><br>- «Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон;<br><br>- «Ведомствоара электрон хезмәттәшлек бердәм системасы турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 8 сентябрендәге 697 номерлы карары |
| Муниципаль заказчы | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаны эшләүче | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты |

| | |
|---|---|
| Программаның максатлары һәм бурычлары | - муниципаль мәгълүмат системаларын кертү;<br>- Нурлат муниципаль районы җирле үзидарә органнары эшчәнлеген тәэмин итү өчен гомуми мәгълүмати-технологик инфраструктураны формалаштыру;<br>- гражданнарга һәм оешмаларга Нурлат муниципаль районы җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында ачык мәгълүматтан, тиешле дәүләт мәгълүмат ресурсларына, шул исәптән Интернет челтәре аша да, керә алу мөмкинлеген бирү;<br>- Нурлат муниципаль районы җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең мәгълүмати иминлеген һәм мәгълүмати-технологик инфраструктура элементларын тәэмин итү;<br>- муниципаль ихтыяҗлар өчен бердәм якланган телекоммуникацион инфраструктураны үстерү;<br>- идарә итү эшчәнлеге практикасына яңа мәгълүмати технологияләр кертү;<br>- мәгълүмати технологияләрне куллану, кирәкле инфраструктураны һәм методик тәэминатны үстерү өлешендә муниципаль хезмәткәрләрнең квалификациясен әзерләү һәм күтәрү буенча комплекслы программаларны гамәлгә ашыру;<br>- мәгълүмати ресурсларның, хезмәт күрсәтүләрнең, мәгълүмати системаларның, технологияләрнең, аларны тәэмин итү чараларының муниципаль базарын формалаштыруга ярдәм итү;<br>- социаль-икътисадый процесслар белән оператив һәм нәтиҗәле идарә итү өчен дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм мәгълүмат киңлеген булдыру;<br>- мәгълүмат системаларын кулланып, Нурлат муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль идарәсенең сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген арттыру;<br>- муниципаль берәмлектә муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оптимальләштерү һәм аларның сыйфатын арттыру;<br>- муниципаль хезмәтләрнең мәгълүмати үтемлелеге дәрәҗәсен күтәрү;<br>- структур бүлекчәләрнең, функциональ органнардагы мәгълүмат алмашуында нәтиҗәлелекне һәм оперативлыкны арттыру;<br>- Татарстан Республикасы ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең региональ системасын (алга таба - ВЭХС) файдаланып, электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтү;<br>- хезмәткәрләрне заманча персональ компьютерлар һәм оргтехника белән тәэмин итү;<br>- компьютер һәм офис техникасын сыйфатлы комплектлау һәм чыгым материаллары белән тәэмин итү;<br>- Нурлат муниципаль районы Советы бинасында һәм Башкарма комитет бинасында локаль исәплә‌ү челтәрен модернизацияләү;<br>- видеокүзәтү системасын модернизацияләү. |
| Программаны тормышка ашыру вакыты һәм этаплары | 1 этап – 2021 ел<br>2 этап - 2022 ел<br>3 этап - 2023 ел |

| | |
|---|---|
| Финанслау күләме | *Район бюджетыннан программаны финанслауның фаразланган гомуми күләме 300,0 мең сум тәшкил итәчәк.* |
| Финанслауның фаразланган күләме | Программаны финанслауның фаразланган күләме 300,0 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>2021 елда – 100<br>2022 елда – 100<br>2023 елда - 100 |
| Финанслау чыганагы | Җирле бюджет |
| Программада катнашучылар | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаны гамәлгә ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм аның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | - яңа мәгълүмати технологияләр базасында идарә итү карарларын кабул итүнең сыйфатын һәм оперативлыгын яхшырту;<br>- идарә итүне оештыруны яхшырту, идарә хезмәтенең нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын күтәрү;<br>- мәгълүмати системаларның өзлексез эшләвен тәэмин итү;<br>- мәгълүмати-техник инфраструктураны камилләштерү;<br>- яңа мәгълүмат системаларын гамәлгә кертү;<br>- ВЭХС ярдәмендә муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтүне оештыру;<br>- мәгълүмати технологияләр өлкәсендә муниципаль хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү;<br>- җирле үзидарә органнарының мәгълүмати ачыклыгын арттыру;<br>- гражданнарның Интернет аша муниципаль район җирле үзидарә органнарының ачык мәгълүматына үтемлелеген тәэмин итү;<br>- административ киртәләрне киметү; |
| Программаның үтәлешен контрольдә тоту | Программаны үтәүне Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының мәгълүматлаштыру һәм мәгълүмати куркынычсызлык бүлеге башкарачак |

## I. Программа хәл итүгә юнәлдерелгән проблеманың характеристикасы, аны программа-максатчан метод белән хәл итү кирәклеген нигезләү

Хәзерге вакытта Нурлат муниципаль районының җирле үзидарә органнарын мәгълүматлаштыру мәгълүматлаштыруны үстерү һәм мәгълүмати технологияләрне куллану мәсьәләләрен регламентлаучы гамәлдәге норматив-хокукый актлар нигезендә үткәрелә:

-«Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында».2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы Федераль закон.

- «Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм мәгълүматлаштыру турында» 2007 елның 13 ноябрендәге 58-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы.

- «Электрон Россия (2002-2010 еллар)» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2002 елның

28 гыйнварындагы 65 номерлы карары белән расланган федераль максатчан программасы;

- «Татарстан Республикасы мәгълүмат ресурслары һәм мәгълүматлаштыру турында» 2004 елның 13 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы;

- «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, фәнни-белем бирү оешмалары һәм бюджет өлкәсе учреждениеләре ихтыяҗлары өчен телекоммуникацияләрнең дәүләт интеграцияләнгән системасын төзү турында» 2004 елның 19 августындагы 1233-р номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы;

- «Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте «комплекслы проектын эшләү һәм гамәлгә кертү эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру турында» 2005 елның 19 гыйнварындагы 39-р номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы;

- «Татарстан Республикасының мәгълүмат ресурслары һәм системалары реестры, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының электрон мәгълүмати хезмәттәшлеген оештыру структурасы, нигезләре һәм тәртибе турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 4 мартындагы 112 номерлы карары;

Муниципаль берәмлек администрациясенең мәгълүмат эшчәнлеге түбәндәге принципларда төзелә:

- үз вәкаләтләре чикләрендә җирле үзидарә органнарының, структур бүлекчәләрнең, администрациянең функциональ органнарының, ведомство карамагындагы учреждениеләрнең муниципаль мәгълүмат ресурсларын формалаштыруда һәм файдалануда мөстәкыйльлеге;

- җирле үзидарә органнары, структур бүлекчәләр, администрациянең функциональ органнары, ведомство буйсынуындагы учреждениеләр тарафыннан гамәлгә ашыру өчен кирәкле һәм җитәрлек күләмдә мәгълүмат ресурсларын формалаштыру;

- җирле үзидарә органнары, администрация структур бүлекчәләре, ведомство буйсынуындагы учреждениеләр эшчәнлегендә кулланыла торган мәгълүматның дөреслеге һәм оперативлыгы;

- муниципаль мәгълүмат ресурслары ачыклыгы;

- гражданнарны җирле үзидарә органнары, структур бүлекчәләр, администрациянең функциональ органнары, ведомство буйсынуындагы учреждениеләр компетенциясе кысаларында кирәкле мәгълүмат белән тәэмин итү мәҗбүрилеге.

Муниципаль мәгълүмат ресурсларыннан файдалану хокукын гамәлгә ашыру тәэмин ителергә тиеш:

- кызыксынган затларның җирле үзидарә органнарының мәгълүмати ресурсларына һәм мәгълүмат системаларына керү өчен шартлар тудыру юлы белән;

- кызыксынган затларның сораулары буенча мәгълүмат бирү юлы белән;

- массакүләм мәгълүмат чараларында җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актларын бастырып чыгару юлы белән;

Шуның белән бергә, финанс ресурсларын озак вакытка исәпләнгән җәлеп итү белән комплекслы бәйләнешне таләп итә торган кайбер проблемалар да бар:

- компьютер техникасы паркын яңарту һәм эшкә сәләтлелеген саклап калу;

- мәгълүмат саклау таләпләрен үтәү буенча чаралар үткәрү;

- район Башкарма комитеты һәм Советы биналарында локаль-исәпләү челтәрен модернизацияләү;
- видеокүзәтү системасын модернизацияләү.

## II Программаның төп максатлары һәм бурычлары, аны тормышка ашыру сроклары, этаплары, максатчан индикаторлары һәм күрсәткечләре

2.1. Программаның максатлары:
- мәгълүмати һәм коммуникацион технологияләрне куллану хисабына муниципаль берәмлек халкының тормыш сыйфатын күтәрү (алга таба - ИКТ);
- җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы мәгълүматка үтемлелек тәэмин итү өчен шартлар тудыру;
- административ киртәләрне киметү;
- муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оптимальләштерү һәм аларның сыйфатын арттыру;
- муниципаль хезмәтләрнең мәгълүмати үтемлелеге дәрәҗәсен күтәрү;
- структур бүлекчәләрнең, функциональ органнардагы мәгълүмат алмашуында нәтиҗәлелекне һәм оперативлыкны арттыру;
- ведомствоара электрон хезмәттәшлек региональ системасын (алга таба - ВЭХС) файдаланып, электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтү.

2.2. Программаның бурычлары:
- мәгълүмати-техник инфраструктураны камилләштерү;
- яңа мәгълүмат системаларын гамәлгә кертү;
- җирле үзидарә органнарының мәгълүмати ачыклыгын арттыру;
- мәгълүмат системаларын яклау, тармак һәм ведомство мәгълүмат системалары базаларының техник һәм мәгълүмати куркынычсызлыгы системасын булдыру;
- региональ ВЭХС кулланып, электрон формада муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру;
- муниципаль функцияләрне электрон формада башкаруны тәэмин итү;
- муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә һәм муниципаль функцияләрне үтәгәндә электрон формада мәгълүмати бәйләнешне тәэмин итү.

2.3. Куелган бурычларны тормышка ашыру өчен муниципаль идарәнең нәтиҗәлелеген күтәрү кирәк. Бу максатларда Стратегик идарә системасын булдырырга, җирле үзидарә органнары һәм муниципаль хезмәткәрләр эшчәнлеген нәтиҗәгә юнәлдерергә, җирле үзидарә органнары функцияләрен оптимальләштерергә, муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын күтәрергә, районның бизнес һәм граждан җәмгыяте белән хезмәттәшлеген көчәйтергә кирәк.

Шулай итеп, Программа муниципаль берәмлектә мәгълүматлаштыру һәм мәгълүмат системаларын үстерү өчен уңайлы шартлар тудыру, муниципаль структураларның һәм район халкының ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен электрон һәм интернет-элемтәнең уникаль мөмкинлекләреннән нәтиҗәле файдалану, дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, физик һәм юридик затларның шәһәр төзелеше, инвестиция һәм башка хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле ышанычлы мәгълүмат белән тәэмин итү, җир төзелеше эшләре алып бару өчен кирәкле ышанычлы мәгълүмат белән тәэмин итү максатларында эшләнде, район муниципаль хезмәтләре эшенең үтә күренмәлелеген арттыру, халыкка хезмәт күрсәтүдән алып электрон рәвештә мәгълүмат бирүгә кадәр, муниципаль хезмәтнең

барлык өлкәләрендә документлар рәсмиләштерүне һәм бирүне гадиләштерү максатларын күздә тота.

| № т/с | Максатчан индикатор һәм күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең эш урыннарын компьютер һәм оргтехника белән тулыландыру һәм яңарту. Программа белән тәэмин итүне яңарту. Видеокүзәтү һәм мәгълүматларны саклау өчен җиһазларны яңарту. | % | 33,3 | 33,3 | 33,4 |